КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 5 май г.Казань № 667

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «837 нче хәрби-исәпкә алу белгечлеге («С» категорияле йөртүче) буенча гражданнарны әзерләүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 18 июнь, 481 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 16 август, 839 нчы; 2023 ел, 24 гыйнвар, 37 нче; 2023 ел, 24 апрель, 520 нче; 2024 ел, 30 декабрь, 1285 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 837 нче хәрби-исәпкә алу белгечлеге («С» категорияле йөртүче) буенча гражданнарны әзерләүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

47 пунктта «исәп-хисап яисә корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

53 пунктның беренче абзацында татар текстында «Бирелгән субсидия» сүзләрен «Субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

54 пунктның беренче абзацында «субсидияне кире кайтару» сүзләрен «субсидия акчасын кире кайтару» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гомуми белем бирү оешмалары укучылары өчен сәнгать-анимация басмаларын бастырып чыгаруга бәйле

чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 30 июль, 665 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 22 июль, 705 нче; 2022 ел, 29 декабрь, 1438 нче; 2023 ел, 21 март, 303 нче; 2024 ел, 30 декабрь, 1290 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Гомуми белем бирү оешмалары укучылары өчен сәнгать-анимация басмаларын бастырып чыгаруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

1.1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

1.5 пунктта татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

8.9 пунктта «исәп-хисап яисә корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

9.5 пунктның беренче абзацында «Бирелгән субсидия» сүзләрен «Субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затларга мәгариф һәм фән өлкәсендә чаралар (конференцияләр, киңәшмәләр, олимпиадалар, симпозиумнар, съездлар, белем бирү сменалары, күргәзмәләр, конкурслар, һөнәри осталык чемпионатлары, шулай ук бүтән чаралар), «Яшь белгеч – киләчәк төзүче» форумын оештыру һәм үткәрү, Татарстан Республикасы җыелма командасының (вәкилләренең) төрле дәрәҗәдәге һөнәри осталык чемпионатларында һәм мәгариф һәм фән өлкәсендәге башка конкурсларга әзерләү һәм аларда катнашу белән бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә (каплауга) субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 9 август, 689 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 23 август, 892 нче; 2022 ел, 29 декабрь, 1438 нче; 2023 ел, 24 апрель, 520 нче; 2023 ел, 8 декабрь, 1589 нчы; 2024 ел, 17 октябрь, 896 нчы; 2024 ел, 30 декабрь, 1287 нче; 2025 ел, 16 июнь, 433 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затларга мәгариф һәм фән өлкәсендә чаралар (конференцияләр, киңәшмәләр, олимпиадалар, симпозиумнар, съездлар, белем бирү сменалары, күргәзмәләр, конкурслар, һөнәри осталык чемпионатлары, шулай ук бүтән чаралар), «Яшь белгеч – киләчәк төзүче» форумын оештыру һәм үткәрү, Татарстан Республикасы җыелма командасын (вәкилләрен) төрле дәрәҗәдәге һөнәри осталык чемпионатларында һәм мәгариф һәм фән өлкәсендәге башка конкурсларда, Халыкара төзелеш

чемпионатында катнашуга әзерләү һәм алар катнашу белән бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә (каплауга) субсидияләр бирү тәртибендә:

1.1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

1.4 пунктта татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

8.7 пунктта «исәп-хисап яисә корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

9.6 пунктның беренче абзацында татар текстында «Бирелгән субсидия» сүзләрен «Субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

9.7 пунктның беренче абзацында «субсидияне кире кайтару» сүзләрен «субсидия акчасын кире кайтару» сүзләренә алмаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, үз структурасында төп эшчәнлек төре булып аутистик спектры бозылган мәктәпкәчә яшьтәге балаларны укыту, тәрбияләү һәм үстерүнең махсус булдырылган шартларында мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программалары, мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган мәгариф программалары һәм өстәмә гомуми үстерү программалары буенча мәгариф эшчәнлеге торган бүлекчәсе булган югары белем бирү мәгариф оешмасына ярдәм күрсәтү» гранты һәм аны бирү тәртибе турында» 2021 ел, 13 август, 721 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 6 март, 213 нче; 2024 ел, 1 октябрь, 845 нче; 2025 ел, 6 февраль, 62 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, үз структурасында төп эшчәнлек төре булып аутистик спектры бозылган мәктәпкәчә яшьтәге балаларны укыту, тәрбияләү һәм үстерүнең махсус булдырылган шартларында мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программалары, мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган мәгариф программалары һәм өстәмә гомуми үстерү программалары буенча мәгариф эшчәнлеге торган бүлекчәсе булган югары белем бирү мәгариф оешмасына ярдәм күрсәтү» гранты һәм аны бирү тәртибе турындагы нигезләмәдә:

1.1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

1.4 пунктта татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

8.9 пунктта «исәп-хисап яисә корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

9.5 пунктның беренче абзацында «Бирелгән грант» сүзләрен «Грант акчасы» сүзләренә алмаштырырга.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Коммерциячел булмаган оешмаларга сәләтле балаларны һәм яшьләрне ачыклау, аларга ярдәм итү һәм аларны озатып бару чараларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән

тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 23 август, 771 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 29 июль, 729 нчы; 2022 ел, 29 декабрь, 1448 нче; 2023 ел, 24 апрель, 520 нче; 2024 ел, 30 декабрь, 1288 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Коммерциячел булмаган оешмаларга сәләтле балаларны һәм яшьләрне ачыклау, аларга ярдәм итү һәм аларны озатып бару чараларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

50 пунктта «исәп-хисап яисә корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

56 пунктның беренче абзацында «Бирелгән субсидия» сүзләрен «Субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт аккредитациясе булган югары белем бирүче программалар – бакалавриат программалары, специалитет программалары, магистратура программалары, аспирантурада (адъюнктурада) фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары, ординатура программалары, ассистентура-стажировка программалары һәм өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча чит ил дәүләтләреннән татар диаспорасы вәкилләрен укытуга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 28 октябрь, 1007 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 12 август, 803 нче; 2022 ел, 29 декабрь, 1444 нче; 2023 ел, 24 апрель, 520 нче; 2024 ел, 30 декабрь, 1284 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Дәүләт аккредитациясе булган югары белем бирүче программалар – бакалавриат программалары, специалитет программалары, магистратура программалары, аспирантурада (адъюнктурада) фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары, ординатура программалары, ассистентура-стажировка программалары һәм өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча чит ил дәүләтләреннән татар диаспорасы вәкилләрен укытуга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

48 пунктта «исәп-хисап яисә корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

54 пунктның беренче абзацында татар текстында «Бирелгән субсидия» сүзләрен

«Субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

55 пунктның беренче абзацында «субсидияне кире кайтару» сүзләрен «субсидия акчасын кире кайтару» сүзләренә алмаштырырга.

7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы шәхси мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан мәктәпкәчә белем бирү, шәхси гомуми белем бирү оешмалары һәм индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 10 ноябрь, 1060 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 10 август, 785 нче; 2022 ел, 29 декабрь, 1438 нче; 2023 ел, 24 апрель, 520 нче; 2024 ел, 15 октябрь, 887 нче; 2025 ел, 28 апрель, 272 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы шәхси мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан мәктәпкәчә белем бирү, шәхси гомуми белем бирү оешмалары һәм индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктның беренче абзацында татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

48 пунктта «исәп-хисап яисә корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

58 пунктның беренче абзацында «субсидияне кире кайтару» сүзләрен «субсидия акчасын кире кайтару» сүзләренә алмаштырырга.

8. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасыннан катнашучыларны төрле дәрәҗәдәге «Ворлдскиллс» стандартлары буенча чемпионатларга әзерләү, «Ворлдскиллс» стандартлары нигезендә чараларны оештыру өлешендә устав эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә коммерциягә карамаган оешмаларга субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 2 август, 747 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 29 декабрь, 1438 нче; 2023 ел, 24 апрель, 520 нче; 2024 ел, 26 октябрь, 927 нче; 2024 ел, 30 декабрь, 1286 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасыннан катнашучыларны төрле дәрәҗәдәге «Ворлдскиллс» стандартлары буенча чемпионатларга әзерләү өлешендә устав эшчәнлеген, «Ворлдскиллс» стандартлары нигезендә чараларны оештыруны финанс белән тәэмин итүгә коммерциягә карамаган оешмаларга субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

1.3 пунктта татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидияләр бирү өчен

бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

7.7 пунктта «исәп-хисап яисә корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

8.6 пунктның беренче абзацында татар текстында «Бирелгән субсидия» сүзләрен «Субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

8.7 пунктның беренче абзацында «субсидияне кире кайтару» сүзләрен «субсидия акчасын кире кайтару» сүзләренә алмаштырырга.

9. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Креатив индустрияләрдә мәдәният, цифрлы технологияләр һәм технологик эшкуарлык өлкәләрендә тикшеренүләр үткәрү, квалификацияле кадрлар әзерләү һәм илнең конкурентлыкка сәләтен арттыру мәнфәгатьләрендә фәнни эшләнмәләрне коммерцияләштерү максатларында «Приоритет-2030» стратегик академик лидерлык программасын гамәлгә ашыру кысаларында югары белем бирү мәгариф оешмасын үстерү программасына ярдәм күрсәтү өчен югары белем бирү мәгариф оешмасына субсидия рәвешендә грант бирү тәртибен раслау турында» 2024 ел, 15 ноябрь, 1013 нче карары белән расланган Креатив индустрияләрдә мәдәният, цифрлы технологияләр һәм технологик эшкуарлык өлкәләрендә тикшеренүләр үткәрү, квалификацияле кадрлар әзерләү һәм илнең конкурентлыкка сәләтен арттыру мәнфәгатьләрендә фәнни эшләнмәләрне коммерцияләштерү максатларында «Приоритет-2030» стратегик академик лидерлык программасын гамәлгә ашыру кысаларында югары белем бирү мәгариф оешмасын үстерү программасына ярдәм күрсәтү өчен югары белем бирү мәгариф оешмасына субсидия рәвешендә грант бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктның икенче абзацында татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

12 пунктта «грант бирү турында» сүзләреннән соң «яисә грант бирүдән баш тарту турында» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле $12^1$ пункт өстәргә:

«$12^1$. Грант бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

оешма әлеге Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәү;

оешма тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмау факты билгеләнү.»;

18 пунктта:

икенче абзацта «шартнамәләр» сүзеннән соң «(килешүләр)» сүзен өстәргә;

өченче абзацта «шартнамәләр» сүзеннән соң «(килешүләр)» сүзен өстәргә;

20 пунктта «исәп-хисап яисә корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга.

10. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2026 елга «Мәктәптә физика-математика алгарышы» гранты турында 2025 ел, 7 июль, 494 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 29 декабрь, 1187 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2026 елга «Мәктәптә физика-математика алгарышы» гранты турындагы нигезләмәгә түбәндәге

үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктта «Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан» сүзләреннән соң «грант бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

56 пунктта:

икенче абзацта «шәхси счетларга» сүзләрен «счетларга» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «шәхси счетларга» сүзләрен «счетларга» сүзләренә алмаштырырга;

61 пунктның беренче абзацында «Бирелгән грант» сүзләрен «Грант акчасы» сүзләренә алмаштырырга.

11. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Фундаменталь, эзләнү һәм (яки) гамәли фәнни тикшеренүләргә, тәҗрибә-конструкторлык эшләренә һәм (яки) тәҗрибә-сәнәгать (кәсеп) сынауларына ярдәм күрсәтү, Татарстан Республикасында дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни-белем бирү үзәгендә катнашучыларның мәгариф программаларын формалаштыру һәм гамәлгә ашыру, фәнни-җитештерү берләшмәләрендә (консорциумнарда) катнашучылар эшчәнлегенә ярдәм күрсәтү, шулай ук Татарстан Республикасында фәнни-популяр һәм сәнәгать туризмын үстерү өлешендә устав эшчәнлегенә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен юридик затка Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2025 ел, 31 октябрь, 883 нче карары белән расланган Фундаменталь, эзләнү һәм (яки) гамәли фәнни тикшеренүләргә, тәҗрибә-конструкторлык эшләренә һәм (яки) тәҗрибә-сәнәгать (кәсеп) сынауларына ярдәм күрсәтү, Татарстан Республикасында дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни-белем бирү үзәгендә катнашучыларның мәгариф программаларын формалаштыру һәм гамәлгә ашыру, фәнни-җитештерү берләшмәләрендә (консорциумнарда) катнашучылар эшчәнлегенә ярдәм күрсәтү, шулай ук Татарстан Республикасында фәнни-популяр һәм сәнәгать туризмын үстерү өлешендә устав эшчәнлегенә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен юридик затка Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

1.8 пунктта татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

7.5 пунктта «исәп-хисап яисә корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

8.4 пунктта:

беренче абзацта татар текстында «субсидия» сүзен «субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта татар текстында «субсидия» сүзен «субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

8.5 пунктта «субсидияне ирекле рәвештә кире кайтарудан» сүзләрен «субсидия

акчасын ирекле рәвештә кире кайтарудан» сүзләренә алмаштырырга.

12. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җәмәгать оешмаларының Татарстан Республикасында компакт яши торган халыклар телләрен саклау һәм үстерү буенча инициативаларына ярдәм» гранты һәм аны бирү тәртибе турында» 2025 ел, 24 декабрь, 1137 нче карары белән расланган Җәмәгать оешмаларының Татарстан Республикасында компакт яши торган халыклар телләрен саклау һәм үстерү буенча инициативаларына ярдәм» гранты һәм аны бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктта татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «грант бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

16 пунктның икенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

53 пунктта «исәп-хисап яисә корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

57 пунктның икенче абзацында «Бирелгән грант» сүзләрен «Грант акчасы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин